# 28 декабрьдә Габдрахман Абсалямовка 110 яшь тулды




Татар әдәбияты классигы, якташыбыз Габдрахман Сафа улы Абсалямов Ковылкино районы Иске Аллагол авылында туып-vсә һәм татар әдәбияты классигы югарылыгын яулый. Анын «Ак чәчәкләрен» татарларыбыз гына тvгел, кvп милләт халкы укып белә. Мордовия татарларыбыз горурланып аны һәрвакыт искә ала. Быел 24нче декабрьдә, Габдрахман Абсалямовнын 110-еллыгын Дубенка районы С.И.Дер-гачёв исемен йорткән Кочкурово урта мәктәбе укучылары, укытучылары белән бергә, искә алдылар. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты предметлары буенча белем бирvче югары категорияле укытучы Альфия Кетдюс кызы Узбякова житәкчелегендә укучылар якташ язучыбызнын биографиясен презентация кулланып сойләделәр. Аннары Г.С.Абсалямов турында фильм карадылар. «Тамчы шоу» уенын да яратып уйнадылар. Бу чараларда актив катнашучылар турында да әйтми калдырып булмый. Ин-ин активлар арасында 7 нче сыйныф укучысы Карина Рахметуллова һәм 8 нче сыйныф укучысы Самира Мусина булдылар.